СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский", Мамадышский район, Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGjr.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 1-5

Боерык
«12» января 2016 года

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Референдум үткәрү инициативасы турында»2015 елның 18 декабрендәге 46 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2015 елның 18 декабрендәге 2-4 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2014 елның 02 апрелендәге 2-33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым салу чараларын җыю һәм куллану тәртибе һәм гражданнарның үзара салым салу турында нигезләмә нигезендә статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2016 елның 28 февраленә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Боек Ватан сугышында һәм хәрби

хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
Жирлекнең торак пунктлары чикләрендә жирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп:
-туфрак сибү, грейдер белән тигезләү - 215,8 мең сум,
Красная Горка авылы, Горький тыкрыгы-200м;
«Мамадыш» совхозы поселогы, Мәктәп урамы-50м, Каюм Насыйри урамы-50 м, Яшьләр урамы -300м,
"Мамадыш" совхозының 2 нче фермасы поселогы, Гагарин урамы-300 м,
Рус Пакшины поселогы, Тынычлык урамы-300 м,
-кардан чистарту һәм жирле әһәмияттәге юлларны тигезләү - 75,0 мең сум.
Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны, урамнар һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны да кертеп):
- Урам яктырту челтәрләренә хезмәт күрсәтү - 80,0 мең сум;
-Территорияне яшелләндерү, урамнар һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру - 50,0 мең сум,

«Әйе» «Юк»

3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек  Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы В.А.Гыйззәтуллина йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гыйззәтуллина